***2нче татар мәктәбенә 110 яшь***

*Кайда юк безнең шәкертләр!*
*Сәламнәр килми кайдан...*
*Яшьлектә янган хыяллар,*
*Яшьлектә безнең дәвам!*

Данлыклы М.Вахитов исемендәге икенче татар мәктәбенең тарих чишмәсе 19 нчы гасыр башларынннан юл ала. Уңайлы пристане булган Чаллы авылы сәүдәгәрләрне үзенә тарта. Вак-төяк сатучылардан тыш анда татар сәүдәгәрләре дә килеп урнаша башлый. Гасыр башында авылда бер мәчет, аның каршында мәктәп-мәдрәсә эшләп килә. Капитализм үсеше чорында аңа дөньяви белемгә ия булган кадрлар кирәк була. Шушы шартларда Чаллыда яңа типтагы җәдит мәктәбе ачу зарурлыгы килеп баса. 1906 елда моңа рөхсәт бирелә. Мәктәп ачуга шул чорда Чаллыда төпләнгән сәүдәгәрләрнең, бигрәк тә беренче гильдия сәүдәгәр С.Хәлфинның шәхси абруе ярдәм иткәндер. Бу мәктәптә дини фәннәр белән бергә дөньяви фәннәр дә укытыла. Мәктәп-мәдрәсә октябрь инкыйлабына кадәр Чаллы татарларының милли-мәдәни үзәгенә әйләнә. Татарстан Республикасы дәүләт архивыннан табылган һәм бүгенге көндә мәктәп тарихы музеенда саклanучы документ моны тулысы белән раслый:

Фонд -3682

Опись-№3

Дело -481

Анкета №58

*Наименование:* Набережночелнинская татарская школа 1 ступени.

*Национальность*: татарская

*Время основания*: 1906 год

*Прежнее наименование*: Челнинский мектеб

*Помещение:* собственное

*Здание:* деревянное

Татар халкының киң катлам ихтыяҗларын канәгатьләндерерлек милли мәктәп совет чорында – 1919 елда ачыла. Шушы елдан башлап берничә мәртәбә мәктәбебезнең юбилейлары зурлап билгеләп үтелә. Совет мәктәбенең беренче мөдире Әхмәтзыя Бикташев була. 1920-1922 еллардагы мәктәп мөдире Зәки Алиев истәлекләрендә күрсәтелгәнчә, ике бүлмәдә балалар укыталар, берсендә укытучылар яши. Беренче укытучыларга эшләү бик авыр була: дәреслекләр җитешми, ачлык комачаулый. Ләкин халыкны караңгылыктан, наданлыктан коткаруга омтылыш авырлыкларны җиңәргә ярдәм итә.

Иж Буби мәдрәсен 1905 елда тәмамлаган Зәки Алиев (Минзәлә районы Кара - Тал авылында туган, Чаллы кантоны оешкач,1923 елдан РОНО мөдире булып эшли, Минзәлә РОНО мәгариф җитәкчесе була) истәлекләре: “1922-23 нче елларда икенче баскыч рус мәктәбеннән бушаган бина татар мәктәбенә бирелә.1923-1924 нче уку елында Теләнче Тамак авылыннан укытучылары белән бергә икенче баскыч татар мәктәбе күчеп килә (5-6 класслар өчен булырга тиеш).1929 елда К.Маркс исемендәге мәктәпне Зәки Алиев белән берлектә Алабугага күчерәләр. Электр – үткәргеченнән янгын чыгып, мәктәп бинасы янып бетә.Беренче баскыч мәктәпне яңадан торгызуга Минзәләдә белем алган һәм акларга каршы сугышып йөргән Арсланова- Әсәтова Зифа зур көч куя.Башкарма комитет инициативасы белән яңа бина җиткерелә. Алга таба мәктәп җидееллык итеп үзгәртелә һәм М. Вахитов исеме бирелә”.Мәктәпкә М.Вахитов исеме бирелүгә бәйле тагы бер истәлек. Ул Татарстанның атказанган укытучысы, Ленин ордены кавалеры мәктәп мөдире Абдукаева Шәмсия истәлекләреннән: “1924 нче елларда мәктәп М. Вахитов урамындагы йортка күчә. Шул еллардан башлап мәктәп М.Вахитов исеме белән йөртелә башлый (Шәһәр ? советы билгеләде булырга тиеш)”. Шулай итеп, егерменче гасырның егеренче-утызынчы елларында мәктәпкә М. Вахитов исеме бирелә.

1931 елда безнең мәктәп җидееллык итеп үзгәртелә һәм аны унөч укучы тәмамлый.Ул елларда мәктәп мөдире булып Уфа гимназиясен алтын медальгә тәмамлаган Хәдичә Зәбирова эшли.Үзеннән соң мәктәпне Әминов Сәлим Гәрәевичка тапшыра. Урта мәктәп статусы сугышка кадәр, 1940 елда бирелә. Бу елларда мәктәптә Зифа Әсәдова, Шәмсия Абдукаева, Әсма Хәйдарова кебек орденлы укытучылар эшли. Алар җитәкчелегендә бик күп файдалы эшләр башкарыла: фронт өчен җылы

киемнәр җыю, фронтка посылкалар җибәрү, бәрәңге киптерү, мәктәп өчен утын әзерләү, ярдәмгә мохтаҗларга булышу һәм башкалар.

1956-1963 елларда мәктәпне шәһәр милли мәгариф системасы үсешенә зур хезмәт куйган һәр нәрсәне алдан күрүче, югары культурага ия  Нәкый Шәйхетдинов җитәкли. Педагогның зур хезмәт нәтиҗәләрен күреп алга таба аны ГорОНО мөдире итеп күтәрәләр. Алга таба ул педагогик эшчәнлеген Зәй, Яңа Зәй һәм Түбән Камада дәвам итә.

1965 елда мәктәп яңа бинага – ГЭС бистәсендәге элеккеге елга лицее бинасына күчә. Анда дүрт ел укыганнан соң, 1969-70 нче уку  елында(Совет мәктәбе ачылуга 50 ел тулган юбилей елында!) КамГЭС мәктәпкә яңа бина төзеп бирә. Бу мәктәп өч катлы, спортзаллы, теплицалы, ашханәле була. Яңа бинаны төзеп керүгә  моңа кадәр Димитров исемендәге 1  мәктәптә  директор булып эшләгән, тумышы белән Спас районы  Юхмач авылыннан  булган РСФСРның халык мәгарифе отличнгы  Михаил Кутузов зур көч куя.

1969 елда 2 мәктәп үзенең 50 еллык юбилеен билгеләп үтә. Мәктәп директоры Кутузов М.Т.ның юбилейда сөйләгән чыгышыннан: “*Мәктәпкә 50 ел.Башлангыч мәктәптән ул урта мәктәпкә әйләнгән. Элек мәктәптә 50 бала укыса, хәзер анда 1500 укучы белем ала.  Элек 2 укытучы эшләсә, хәзер70 педагог белем бирә. Данлы 50 еллык юл үттек”.*

КамАЗ төзелә башлагач, Чаллыга бик күп кеше килә. Мәктәптә балалар саны ике меңнән артып китә, дәресләр 2-3 сменада укытыла. Бу елларда безнең мәктәп татар- рус мәктәбе булып эшләвен дәвам итә.

1975 елның 15 декабрендә мәктәптә М.Вахитов музее ачыла. Музейны оештыруда  директор җитәкчелегендә  Бәһрия Җамалиева һәм Анна Солтанова-Бустерякова  материал туплыйлар, күп төрле  эзләнү эшләре алып баралар.  Башта Язучылар идарәсе белән элемтәгә керәләр, М.Вахитовның  ике туганы рәссам Казаков аша М.Вахитовның туганнары белән элемтәгә чыгалар, шәхси әйберләрен алып кайталар. М.Т.Кутузов  ярдәме белән кичә оештырыла, музей ачыла.

Алга таба  Михаил Кутузов 12, 13 мәктәпләрдә директор булып хезмәт куеп лаеклы ялга чыга

1977 елдан алып тугыз ел М.Вахитов исемендәге 2 нче рус-татар мәктәбендә директор булып тәҗрибәле, эрудицияле җитәкче Ирек Уразаев эшли.

17ел барлык мөмкинлекләре тудырылган бинада укыганнан соң, 1986-87 уку елында (Мәктәпкә 80 яшь!), Волгоград физкультура институты филиалына бина кирәк булу сәбәпле, татар классларында укучылар саны 250 гә калуны сәбәп итеп (1981 елда Яңа шәһәрдәге 24 мәктәптә ачылган татар классларында балалар саны 500 дән артып китә! ), коллективны вакытлыча 44 нче мәктәпкә күчерәләр. Мәктәп ул бинада 1986- 1989 нчы елларда эшли. Бу елларда татар телен һәм татар мәктәпләрендә рус телен укытуның сыйфатын күтәрүдә РСФСР ның атказанган укытучылары Ә.Х.Садыйкова, Г.Н.Шамматова, РСФСР халык мәгарифе отличнигы Анна Ивановна Солтанова- Бустерякова, РСФСР халык мәгарифе отличнигы С.Ә.Сафиуллина зур хезмәт куялар. Рус теле укытучысы ӘлфияХәбриевнаның Садыкованың хезмәт кенәгәсендә бары бер язма: 2 мәктәп !

Уңышларга ирешеп эшләүче мәктәпкә 1985-86 уку елында татар мәктәбе статусы кайтарыла.1989 елда 32нче бистәдә җиде ай эчендә хәзерге яңа бина өлгертелә. Яңа шәһәрнең 45 мәктәбендәге татар класслары белән кушылып, 2 мәктәп яңа бинага күчә. Нәкъ менә Фоат Нуруллин эшләгән вакытта 2 мәктәпкә татар мәктәбе статусы кире кайтарыла. Бинаны төзүдә татар җәмәгатьчелеге һәм укытучылар белән берлектә мәктәп директоры Фоат Нуруллин зур хезмәт куя. Мәктәп төзетү эшләре белән яшь директорга көн-төн эшләргә туры килә. ” 2 спортзалы, бөтен мөмкинлекләре булган мәктәп проектын эзләп табу миңа тапшырылды. Минем киңәш буенча проектка үзгәрешләр кертелде”,- дип искә алды телефон аша сөйләшкәндә Фоат Калимуллович.

1989 нчы елның февраль аенда бина төзелә башлый һәм 1989-1990 нчы уку елының 1 сентябренә- Белем бәйрәменә 32 бистәдә яңа мәктәп бинасы ачыла. Мәктәп 7-8 айда төзелеп бетә.(12 мәктәп билгеләнгән 1ел урынына 4 айда төзелә).

Мәктәп бинасының эчке һәм тышкы ягын ТР ның Атказанган сәнгать эшлеклесе, Мәскәүдәге Суриков исемендәге сәнгать институтын тәмамлаган тумышы белән Курган өлкәсе Әлмән районы Тозау авылыннан булган, яшьлек елларын Таҗикстанда үткәргән себер татары Ким абый Сафиуллин милли орнаментлар, рәсемнәр белән бизи, Ул - сугышта һава стрелогы булып катнашкан

сугыш ветераны.1990 елда Республика мөстәкыйльлеге кабул ителгән көннәрдә кыю холыклы Ким Сафиуллин Казанда халыкка мөрәҗәгать белән чыга.(Чаллы шәһәре энцеклопедиясе, 316 б)

Татар мәктәбен кабат ачу һәм үз бинасын булдыру буенча зур хезмәт куйган татар җәмәгатьчелегенең тагын бер вәкиле Раиф абый - тумышы белән Казан кешесе, туган телен камил белгән зыялы кеше иде.

1990-1991 уку елыннан мәктәбебез мәктәп-гимназия итеп үзгәртелә. Ә 1998 елда ул гимназия статусын ала. Гимназиянең беренче директоры – һәрвакыт яңалыкка омтылучы, милли җанлы Рәфкать Муллин. Узган гасырның туксанынчы елларында милли мәктәпләр ачу һәм аларның статусын күтәрү парламент югарылыгына куела. Иң авыры- гимназияләр өчен аерым уку- укыту планнары, программалар булмау.Ул вакытта мәгариф министрлыгында баш белгеч булып эшләгән Рәфкать Муллин истәлекләреннән: “Әле дә хәтеремдә, бер җыелышта атаклы галим, мәгърифәтче Мирза Мәхмүтов “ иң әүвәл программалар, дәреслекләр һәм педагогларны әзерләргә, аннары гына татар гимназияләре ачарга кирәк”, дип чыкты. Ләкин мин батыраеп, Мирза Исмәгыйлович, *фәлсәфәдә* эчтәлектән формага һәм формадан эчтәлеккә бару юллары да саклана. Әгәр без программалар, китаплар, укытучылар, биналар көтеп ятсак,бүгенге мөмкинлекләрне ычкындырабыз.... дидем”

Педагог күп мәсьәләләрдә хаклы булып чыга.Гимназия оештырганда барлык эшләр дә параллель бара. “Без Европа һәм рус классик гимназияләренең иң яхшы сыйфатларын үз эченә алып, Габдулла Бубилар, Фатима Аитовалар оештырган шикелле үз йөзе булган уку йорты төзергә тиеш. ... Без Көнбатышның дөньяви белемнәрен, ә көнчыгышның, үзебезнең халыкның меңнәрчә еллык гыйлемебезне бергә кушып эшләсәк кенә, татар гимназияләренең үз йөзен булдыра алачакбыз”,- дип һәрвакыт искәртә иде хөрмәтле мөгаллим.

Гимназия ачылган елда беренче сыйныфларда 8 класс бала укый. Мәктәптә элек белем алган укучылар да саклап калына: башта ул мәктәп- гимназия булып эшли.”Бу әйбәт юл булды: бер генә укытучы да рәнҗеп калмады.Кеше, бигрәк тә сабыйлар, ата-ана һәм укытучылар рәнҗешеннән дә авыр нәрсә юктыр” дип искә алган РСФСР халык мәгарифе отличнигы Рәфкать Муллин ул елларны. Укучыларга күп мөмкинлекләр тудырыла, аларны гимназиягә шәһәрнең төрле почмакларыннан 7 автобус йөртте. Укучыларга өстәмә белем бирү буенча аеруча

күп эш башкарыла. Бу елларда 2 нче гимназия шәһәр милли мәгарифен күтәрүгә дә булышлык итә. Биналары өлгереп җитмәгән 54 нче татар гимназиясе, 56 нчы мәктәп, 13нче татар сәнгать мәктәбен, төрек-татар лицейларын вакытлыча үз бинасына сыендыра, укыту-тәрбия процессын оештыруга ярдәм итә.

1994 елдан 2011елга кадәр уку йортын зыялы шәхесләрнең берсе - Татарстанның атказанган укытучысы, мәгариф отличнигы Дания Йосыпова җитәкли. Ул эшләгән дәвердә уку йорты мәктәп- гимназиядән чын мәгънәсендә гимназиягә әйләнде: аттестация үтте һәм лицинзия алды. Гимназия алдына куелган күп бурычлар хәл ителде.

Дания Шамил кызы 2011-2012 уку елында директорлык вазифасын яшь, белемле Фирдүсә Әюповага тапшыра.

Чирек гасыр ел эчендә зыялы, туган телен камил белүче һәм тарихын хөрмәт итеп халкына хезмәт итүче яңа буын үсеп чыкты. 2-3 буын балалары 2 мәктәптә белем алып, буыннар чылбырын дәвам иткән гаиләләр гимназиядә бик күп булу- уку йортының бүгенге көндә абруы зур булу турында сөйли.Гимназиянең яшь укытучылар белән тулыланып торуы сөендерә. Шушы мәктәптә белем алып гомер буе туган мәктәпләренә хезмәт иткән Анна Солтанова, Бәһрия Җамалиева, Гүзәлия Әхмәдиева, Наил Гыйззәтуллиннар (һәм тагын шундый бик күпләр!) эстафетасын бүген яшь укытучылар Альбина Рахматуллина, Ләйсән Шәйгәрданова, Альбина Фәтхуллина дәвам итә.

*Бүген көндә гимназиядә 998 укучы белем ала, аларга 64 укытучы белем бирә.* Укытучыларның 29ы (46%) – югары, 22се (38%) – беренче категорияле. Педагоглар арасында “Татарстанннның атказанган укытучысы” ( 1укытучы), “СССРның мәгариф отличныгы” (1), “Халык мәгарифе отличнигы” (6) исеменәрен йөртүче укытучыларыбыз бар. Бер укытучы – “РФ мәктәпләренең мактаулы хезмәткәре” билгесе, икесе “Мәгариф каршындагы казанышлары өчен” билгесе белән бүләкләнгән.

Гимназиядә тәҗрибәле кадрлар эшли. Укытучының 62% ының эш стажы 20 елдан артык.

Мәктәпне төрле елларда тәмамлаган укучылар арасында югары дәрәҗәләргә ирешкән дәүләт эшлеклеләре, галимнәр, төрле дәрәҗәдәге оешма, учреждение җитәкчеләре, эшмәкәрләр һәм башка һөнәр ияләре күп. Мирсәет Төхвәтуллин – Дан

орденнарының тулы кавалеры;чыгышы буенча Зәй районы Югары Баграж авылыннан булган экономик фәннәр докторы, професор, “Салкын” Халыкара академиясе әгъзасы, Ленин һәм Хезмәт Кызыл Байрагы кавалеры, “КВАРТ” резинотехника ябык акционерлык җәмгыяте генераль директоры Вениамин Григорьев – Социалистик Хезмәт Герое, Валерий Дмитриев – дүрт иптәшен коткарып үзе һәлак булган әфганчы, СССР спорт мастеры Надежда Кибардина – велоспорт буенча олимпия, дүрт тапкыр дөнья чемпионы. Татарстанның халык актрисасы Г.Казанцева һәм “ Ташпулат” татар операсында төп рольләрнең берсен уйнаган яшь артист Р.Гатин - М.Җәлил исемендәге опера һәм балет театры артистлары.

Соңгы елларда уку йортларына таләпләр тагы да артты. Шундый бай тарихы, хезмәт тәҗрибәсе булган гимназиядә эшләү безгә үтә җаваплылык өсти. Бу җаваплылыкны эшләгән саен күбрәк аңлыйсың.

Ә уку йортының гасырдан артык тарихына, эшчәнлегенә йомгак ясап кую - 110 еллык юбилеен тантаналы төстә билгеләп үтү – коллективның, шулай ук безгә кадәр эшләгән буыннарның хезмәтенә йомгак ясау этабы ул.

*Тәрбия эшләре буенча директор урынбасары Харисова Э.М.*